| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Мунайкинского сельского поселения<br>Менделеевского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Монай авыл жирлеге Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

26 август 2023 ел № 105

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге Советының
карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-09/1230 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 120 номерлы карары,
   «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2015 елның 19 ноябрендәге 121 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылыкны, хокук тәртибен, депутат этикасын саклау буенча даими комитетка йөкләргә.

Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов